# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында" 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $11^1$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

"$11^1$ статья. **Татарстан Республикасында дарулар, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, дезинфекция чаралары, иммунобиологик препаратлар сатып алуны, медицина техникасын ремонтлауны һәм аңа техник хезмәт күрсәтүне оештыру**

Татарстан Республикасы медицина оешмаларын дарулар, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, дезинфекция чаралары, иммунобиологик препаратлар белән тәэмин итү, медицина техникасын ремонтлау һәм аңа техник хезмәт күрсәтү максатларында дәүләт учреждениесе яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ведомство буйсынуындагы һәм аның тарафыннан билгеләнә торган дәүләт унитар предприятиесе бердәнбер тәэмин итүче (башкаручы) буларак түбәндәгеләрне тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең сәламәтлек саклау өлкәсендә вәкаләтле органы, гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасын гамәлгә ашыруда катнаша

торган Татарстан Республикасы медицина оешмалары өчен дарулар, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары, дезинфекция чаралары, иммунобиологик препаратлар сатып алу, аларны саклау һәм илтеп тапшыру;

2) дарулар, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән түләүсез тәэмин ителү хокукына ия гражданнар өчен дарулар, медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары сатып алу, аларны саклау, илтеп тапшыру һәм биреп җибәрү;

3) гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган Татарстан Республикасы медицина оешмалары өчен медицина техникасын ремонтлау һәм аны техник яктан карау буенча хезмәтләр күрсәтү;

4) федераль программаларны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасына федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелә торган даруларны, медицина әйберләрен һәм иммунобиологик препаратларны саклау һәм Татарстан Республикасы медицина оешмаларына илтеп тапшыру.".

**2 статья**

Әлеге Закон 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 26 декабре
№ 104-ТРЗ